| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 сентябрь № 629

г. Казань

«Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 1 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен төзү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 15 февраль, 79 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турында нигезләмәнең 4 пунктындагы 7 пунктчаны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 1 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә, Учреждение эшчәнлегенең төп максаты итеп оешмалар мөлкәтен шартнамәле нигездә янгыннардан саклауны тәэмин итү дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

ике ай эчендә Учреждение уставын расларга һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралган кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашырырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Учреждениенең штат саны 818 берәмлек тәшкил итә;

Учреждениене финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш

хәлләр министрлыгы» ведомствосы буенча әлеге максатларга каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков